ГЛАВА
НОВОАРЫШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422668, Республика Татарстан,
Рыбно-Слободский район, Школьная ул., дом 30,
с.Новый Арыш, 422656

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА АРЫШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

422668,Татарстан Республикасы,
Балык Бистәсе районы, Мәктәп урамы, 30 нчы йорт,
Яңа Арыш , 422656

Тел.: (8-4361) 25-782 , факс: (8-4361) 25-782 , эл.адрес: Nars.Rs@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2022 елның 11 ноябре Яңа Арыш авылы № 7

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлегенең Яңа Арыш авыл торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июлендәге ”Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 45-ЗРТ номерлы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Яңа Арыш авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 22 маддәсе нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлегенең Яңа Арыш авыл торак пунктындаүзара салым кертү буенча гражданнар җыенының беренче этабын 2022 елның 26 ноябрендә 9 сәг. 00 минутка билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлегенең Яңа Арыш авыл торак пунктында үзара салым кертү буенча гражданнар җыенының икенче этабын 2022 елның 26 ноябрендә 13 сәг. 00 минутка билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлегенең Яңа Арыш авыл торак пунктында үзара салым кертү буенча гражданнар җыенының өченче этабын 2022 елның 26 ноябрендә 15 сәг. 00 минутка билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлегенең Яңа Арыш авыл торак пунктында үзара салым кертү буенча гражданнар җыенының дүртенче этабын 2022 елның 27 ноябрендә 09 сәг. 00 минутка билгеләргә.

5. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлегенең Яңа Арыш авыл торак пунктында үзара салым кертү буенча гражданнар җыенының бишенче этабын 2022 елның 27 ноябрендә 13 сәг. 00 минутка билгеләргә.

6. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлегенең Яңа Арыш авыл торак пунктында үзара салым кертү буенча гражданнар җыенының дүртенче этабын 2022 елның 27 ноябрендә 15 сәг. 00 минутка билгеләргә.

7. Гражданнар җыенын үткәрү өчен торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген бүлү территориаль билге буенча гамәлгә ашырылуын расларга.

8. Гражданнар җыены каравына куела торган сорауны расларга:

Сез 2023 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлегенең Яңа Арыш авыл торак пунктында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (уку йортларына йөреп укучы студентлардан гайре) 300 сум күләмендә үзара салым акчасы кертүгә һәм тупланган средстволарны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга ризамы:

- Яңа Арыш авылында юллар ремонты өчен вакланган таш сатып алу;
- транспорт хезмәтләре өчен түләү;
- кышкы чорда Яңа Арыш авылында юлларны карап тору
- скважинаны рәсмиләштерү өчен түләү;
- пожарный насосы сатып алу;

"ЯКЛЫЙМ" "КАРШЫ"

9. Әлеге карарны дәүләт теркәвеннән соң Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлегенең түбәндәге адрес буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендында урнаштырырга: Яңа Арыш авылы, Мәктәп урамы, 30 йорт һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"нда.

10. Карар басылып чыккан (халыкка белдерелгән) көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Яңа Арыш авыл җирлеге башлыгы Х.С.Зарипов